ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕОШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур., 54 а нче йорт, Югары Ушма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

№ 15 — 25.12.2025 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге гражданнарынын

2025 елның 27 нче октябрь 1 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Алкин торак пунктында 2026 елга үзара салым кертү турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 2 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Алкин торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 3 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Хәсәншә торак пунктында 2026 елга үзара салым кертү турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 4 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Хәсәншә торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 5 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Ак Чишмә торак пунктында 2026 елга үзара салым кертү турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 6 нчы санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Ак Чишмә торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 7 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Иске Завод торак пунктында 2026 елга үзара салым кертү турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 8 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Иске Завод торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 9 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Комазан Урманчылыгы торак пунктында 2026 елга үзара салым кертү турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 10 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Комазан Урманчылыгы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 11 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Югары Ушма торак пунктында 2026 елга үзара салым кертү турында»гы

2025 елның 27 нче октябрь 12 нче санлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Югары Ушма торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы
карарларын тормышка ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар бирэ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе / И.З.Исмагилов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы
Югары Ушма авыл
җирлеге
Башкарма
комитетының
25.12.2025 ел, 15 нче
санлы карарына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2026 елның 26 нчы мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге
Башкарма комитетының 25 нче декабрь 2025 ел,
15 нче санлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш Муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге

(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_____________________________________________________________

Адрес: __________________________________________________________________

Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең ______авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2021 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 26нчы март 2021 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ___сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: УФК по РТ (Финансово-бюджетная палата Мамадышского муниципального района РТ)

Кабул итүче як банкы

Сч. №

Кабул итеп алучы Сч. № ________________________________________

ИНН

КПП
КБК
ОКТМО
Түләүнең билгеләнеше: Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче __________________ __________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**

__________________________________________________________

(*муниципаль берәмлек исеме)*

_________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № __________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.

__________________________________________________________

Адрес:

________________________________________________________________________

«__» ________________ 20__ г. _________________________________________

(түләүченең имзасы)